ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ


# «КӨЗГЕ»

КӨЗГЕ

апрель,
2018 нче ел

№8 (38)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**




**Көндез—кояш, кичен ай
яктырта
Бу дөньяда зәңгәр күк
йөзен
Татар шигърияатен
балкытучы
Юл салучы—Тукай ул
безнең!**

*Әһлиуллина Гөлназ*

**12—Космонавтлар көне**

**26— Габдулла Тукай туган көн**

## Тукай – туган абыем!

Кем батырчылык итәр
Мине нәни дияргә?
Өйрәндем күп әкиятләр
Һәм шигырьләр сөйләргә.
Укыган саен укыйсы
Килүнең сере нидә?
Әсәрләре мавыктыргыч,
Кызыклы, туган телдә!

Барысының авторы бер –
Габдулла абый Тукай.
Аны шулкадәр яраттым,
Без бит туганнар бугай?!
Апа белмичә әйтмидер:
“Тукай – телебез шаһы”.
Моңа шагыйрьнең тормышы,
Олы иҗаты шаһит.

Әһлиуллин Аяз

УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

## Тукайны бел

Мавыктыргыч әкиятләр
Язган Тукай агабыз,
Тагын да кызыклы үтсен
Диеп балачагыбыз.
Күпме шигырь иҗат иткән,
Тәнкыйть мәкаләләре...
Теле гади, аңлаешлы,
Үткен, тирән мәгънәле.

Бик аз гомер иткән шагыйрь,
Иҗат еллары кыска,
Ә шулай да бөек эшләр
Башкарган халкыбызга.
Тукай аша белдем телне,
Тел аркылы – Тукайны.
Телне, Тукайны белгәннәр
Саклап калыр татарны!

**Бу санда:**

Габдулла Тукай - 1
Сәламәтлек көне 2
Георгий тасмасы 3
Апрель аенда сынамышлар 4
Конкурслар 5
Котлыйбыз 6

## 12 нче апрель—космонавтика көне.










19961 нче елның 12 нче апрелендә СССР да галәм киңлекләре ачыла.Шул көннән алып ел саен Галәм геройларын искә алабыз. Фома мәктәбенең башлангыч сыйныф укучылары галәм, космонавтика, Юрий Гагарин темалыраына иҗат җимешләре булдырды. Һәр сыйныфта тәрбия сәгатьләре үткәрелде.Сезнең дә игътибарга тәкъдим итәбез. Будь в курсе последних событий!







## 7 нче апрель  көнне мәктәптә сәламәтлек көне флешмоб  белән башланып китте...











## Җиңү көне якынлаша







Республикада «Георгий тасмасы» акциясе старт алды. Анда 6.5 мең волонтер катнаша. 9 Май— Бөек Җиңү көненә кадәр алар кешеләргә 15 мең тасма таратачак. Акция тантаналы төстә Казанның Горький паркында ачылды. Волонтерлар буларак әлеге акциядә студентлар оешмаларыннан, шул исәптән 2016 елда оешкан «Җиңү волонтерлары» хәрәкәтеннән егетләр һәм кызлар үз өлешен кертә. Волонтерлар георгий тасмасын ничек тагарга икәнлеген дә аңлата. Аны сумкага, түшкә, йөрәккә якын урынга тагарга кирәк. Безнең мәктәп тә бу акциядән читтә калмады. Авыл халкы да бу акциягә актив катнашты.

## Без «Ялкын» журналының «Лидерлар мәктәбе»ндә




**“Лидерлар мәктәбе” кабат тулы көченә эшли башлады. Каршы алыгыз: “Ялкын” журналының май санында кабат – “Лидерлар мәктәбе”. Бу юлы безне Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Шәйхразиев Васил Габтелгаяз улы үзендә кунак итте.**

Яраткан журналыбыз «Ялкын»ның “Лидерлар мәктәбе” балалар редколлегиясенә республикабызның иҗат белән шөгыльләнүче, китап сөюче укучылары керә.
19 нчы апрель көнне башкалага барырга мөмкинлек тапкан безнең редколлегия вәкилләре һәм “Лидерлар мәктәбе” катнашучылары Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары Васыйл Гаяз улы Шәйхразиев белән Министрлар кабинеты бинасында очрашуда булып кайттык. Без Хөкүмәт үзәге буенча экскурсиядә булдык һәм утырыш залларын карадык.
Васыйл Гаяз улы зур кеше булса да, гади, бик итәгатьле икән. Аның белән сәгатьләр буе спорт турында да, ат чабышлары турында да сөйләшеп була, тавышын тыңлап туймассың. Очрашу барышында премьер-министры урынбасары безнең сорауларга бик теләп җавап бирде. Иптәшләрем уңыш сере, тормыш мәгънәсе турында кызыксындылар. Васыйл Гаяз улының армиядә булган еллары,балачак турында да белдек. Мин аңа: "Мәктәптә сезгә кайсы фәннәр җиңел бирелә иде?"- дигән сорау белән мөрәҗәгать иттем. "Яраткан фән күбесенә җиңел бирелә.Шулай ук яраткан фән,беренчедән,сәләттән,ә икенчедән,укытучыдан тора бит.Уземнең яраткан фәннәрем:география,тарих һәм математика иде.Укыган вакыт тиз утеп китә шул.Мәктәп еллары - иң матур,иң күңелле чак."-дип җавап кайтарды ул миңа.
Искиткеч тәэсирләнеп кайттым мин ул очрашудан. Кыскасы, очрашу бик күңелле узды. "Ялкын"ыма аеруча олы рәхмәт. ***Алинә Нямаева***

# Апрель аена халык сынамышлары



Апрель ае керүгә карамастан, урамда һаман да әле кыш белән яз тартыша. Синоптиклар 2018 елның язы вакытыннан иртә килде дип белдерсә дә, җылы кояшлы көннәр аралаш карлап-буранлап та ала. Халык исә һәр күренешне гасырлардан килгән сынамышлар аша юрый.

Апрель артык җылы булса, май салкын, җилле булыр.

**Апрельнең бишесендә Хозыр-Ильяс камчы селти.**

**Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшы килә.**

**Апрель яңгырлы булса, гөмбә уңар.**

**Ай башында яшен яшьнәсә, җәй җылы килер һәм чикләвек мулдан булыр.**

**Апрельдә көндез кызу, төнлә салкынча булса, җылы җәй юрыйлар.**

**Ай ахырында төннәр йолдызлы булса, уңыш уңар. Шулай ук айның соңгы ун көнендә яңгырлар яуса да, ел уңдырышлы булыр.**

**Апрельдә каен суы күп акса, җәй яңгырлы килер.**

**Апрельдә карлыгачлар килмәсә, ясалкын язга.**

**1 апрельдә һава торышы нинди булса, октябрьнең беренче көне дә шундый булыр. Йолдызлар күренмәсә, җылы көннәр җитә дигән сүз.**
**2 апрельдә елгадагы бозлар тиз агым белән китсә, икмәк уңар. Әгәр көн суык булып, кошлар чыркылдашса, җылы җәйгә.**
**3 апрельдә сулыкларда боз китмәсә, балыкчылар язгы "ау"ны көтмәсен.**
**4 апрельдә кояш кызарып баеса, яшелчә уңышы уңар. Ала каргалар коенса, җылыта.**
**5 апрельдә аяз төн - иртәнге суыклар билгесе.**
**6 апрельдә төн җылы булса, яз матур килер.**

**7 апрельдә көн җилле, бәс яки томан булса, уңышлы ел килә.**
**8 апрельдә көн нинди булса, 8 октябрьдә дә шуны көт.**
**9 апрель көнне көндез әтәч кычкырмаса, 2-3 көннән явым-төшем булыр.**
**10 апрельдә кояш кызарып чыгып, тиз арада болыт артына качса, яңгыр явар.**

# Конкурслар



Казанда апрель аенда булып узган 8 нче Халыкара Г.Тукай исемендәге укучылар конкурсына безнең мәктәптән 9 нчы сыйныф укучысы ӘһлиуллинАяз «Ана—бөек исем» темасы астында чыгыш ясап диплом белән бүләкләнде. Сәләтле балалар хәйрия фонды оештырган15 нче фәнни гамәли конференциясендә «Күркәм халык—җан зиннәте» докладын укыды һәм 2 нче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

Әфәрин, Аяз!



2 нче апрель көнне безнең Фома авылы мәктәбенең 4,5,6 сыйныф укучылары район буенча үткәрелгән „Куркынычсызлык тәгәрмәче " дип исемләнгән бәйгедә катнаштык. Бәйгенең төп максаты балаларны юлда йөрү куркынычсызлыгы кагыйдәләрен саклауга чакыру булды.Мәктәбебез данын яклау өчен Таһиров Ильмир,Вильданов Рәмзил,Сөнгатуллина Рәзилә һәм мин Закирова Гөлинә бер команда булып уңышлы гына чыгыш ясадык һәм район мәгариф җитәкчелегеннән мактаулы рәхмәт сүзе алдык.
Закирова Гөлинә






Фома авылы мәктәбендә алтын куллы укучылар укый. Алар быел апрель аенда республика күләмендә үткәрелә торган агачтан ясалган "Агач күңеле" дип аталган ачык конкурста катнашалар.

Зиннуров Рәзил үз куллары белән балалар өчен юкә агачыннан бик зәвыклы комод яса-

бүгенге көн таләпләренә яраклаштырылып эшләнелгән.

Гирфанов Инсаф чәчәкләр аскуймасы иҗат иткән. Мондый аскуйма стенага беркетелеп куела һәм хуш исле чәчәкләргә күмелә.




Апрель аенда туучы
кадерле укучыларыбыз!

**Галиуллин Әлфис, Шагиахметов Илназ, Сандимирова Вероника, Тагиров Булат, Каняфин Рамил!**

**Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.**

**Озын булсын гомерегез,**
**Тыныч булсын күңелегез.**
**Бәхет чишмәләрегез мул аксын,**
**Зур шатлыклар белән таң атсын!**

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз Илфат улы

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Әһлетдинова Гөлләр, Гайнуллина Алия, Гайсина Вероника, Закирова Гөлинә, Масгутова Гөлназ, Хайруллина Әдилә, Хисматова Зәринә